**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

__26.02.2018_ __164-п__

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыруга биремнәр һәм аларның эчтәлекләрен рәсмиләштерү һәм юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль законның 8.3 статьясына ярашлы рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2017 елның 06 декабрендәге 1465-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыруга биремнәр һәм аларның эчтәлекләрен рәсмиләштерү һәм юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Интернет» челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштырылганда зарури таләпләр үтәлешен күзәтү;»;

түбәндәге эчтәлекле тугызынчы абзац өстәргә:

«– территорияләрне һәм акваторияләрне планлы (рейд белән) караулар (тикшерүләр).».

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.Е.Никулин) шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Бу боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары Ф.Ф. Шакировны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В. Шадриков